**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Чарлы авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 10 ноябре** **№ 3**

**Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 24 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Чарлы авылы, Яшьләр урамы, 10 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 24 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Чарлы авылы, Яшьләр урамы, 10 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлар); 18 яшькә кадәрге балалар тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәкләрдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- кышкы һәм җәйге чорда Чарлы авылы юлларын карап тоту;
- янгын куркынычсызлыгы (янгын куркынычсызлыгы рукавлары, рукавларны саклау тартмалары, авариягә каршы автоматика контроле янгын сүндерү колонкаларын сатып алу);
- төзекләндерү: агачларны (тирәк, юкә) кисү;
- юл билгеләре урнаштыру: «Балалар мәйданчыгы», «Тизлекне чикләү»;
- спорт мәйданчыгына баскетбол калканнары сатып алу һәм урнаштыру;
- Чарлы авылы торак пунктына видеокүзәтү чараларын сатып алу һәм урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Чарлы авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чарлы авыл җирлеге башлыгы Э.Н. Козлов